**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодур авыл җирлеге Советы карары**

Чемодур авылы №20 18.08.2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодур авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2012 елның 17 октябрь 52 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Чемодур авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (2013 елның 9 сентябрь72 номерлы, 2014 елның 18 март 89 номерлы, 2014 елның 18 август 108 номерлы, 2017 елның31 август 59 номерлы, 2018 елның 13 ноябрь 104 номерлы карарлар редакциясендә)

2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чемодур авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чемодур авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатында,

Чемодур авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодур авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2012 елның 17 октябрь 52 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Чемодур авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (2013 елның 9 сентябрь72 номерлы, 2014 елның 18 март 89 номерлы, 2014 елның 18 август 108 номерлы, 2017 елның31 август 59 номерлы, 2018 елның 13 ноябрь 104 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.11.13 пунктта:

а) «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга;

б) «ТБО» аббревиатурасын «ТКО» аббревиатурасына алмаштырырга.

1.2. 2.11.16 пунктта «ТБО» аббревиатурасын «ТКО» аббревиатурасына

алмаштырырга.

1.3. Түбәндәге эчтәлекле 2.11.18 пункт белән тулыландырырга:

«2.11.18. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чемодур  авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләре авыл җирлеге Башкарма комитетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Н.Б.Котельникова